**Межрегиональные предметные олимпиады КФУ**
**профиль «Татарский язык»**
**Заключительный этап**
**ОТВЕТЫ**
**2022-2023 учебный год**
**9 класс**

**I. Ябык иҗекләрдән генә торган 10 сүзле җөмлә уйлап языгыз. / Напишите предложение из 10 слов, состоящие только из закрытых слогов.** (10 баллов. *За каждое верное слово по 1 баллу* ).

*Мәсәлән, Тормыш җайлангач, йортын зурдан корган: җил- яңгыр үтмәслек, дошман сөйләрлек булган.*

***II.*** **Хәрефләрне дөрес тәртиптә урнаштырып, сүзләрне табыгыз. Алардан мәкаль төзегез. /** Составьте из букв слова, из слов - пословицу. (10 баллов. *За нахождение слов 5 баллов, за составление пословицы 5 баллов).*

*АРОТ МҢЕ РЕБ МАГЛИ АДНАГАН*

*Бер галим мең наданга тора.*

***III.*** **Төшеп калган сүзләрне, кирәкле формага куеп, текстта өстәп языгыз. /** Запишите пропущенные слова, поставив в нужной форме. (10 баллов. *За каждый правильный ответ по 1 баллу*).

Шагыйрь сүзе ике 2 1) **иҗектән** тора. Сүздә 2) **дүрт** тартык аваз бар. Сузык авазлары - [а] һәм 3) **[и].** Сүз сингармонизм законының рәт гаромониясенә 4**) буйсынмаган.** Сүзнең әйтелеше белән язылышы арасында аерма 5) **бар.** Шагыйрь сүзенә 6) **нечкә** кушымча ялгана, чөнки 7) **соңгы иҗек нечкә**. Бу сүз - 8) **гарәп** алынмасы. Ул 9) **шигырьләр язучы ир кеше** дигәнне аңлата. Хатын-кызга карата 10) **шагыйрә** диләр.

**IV. Җөмләгә 1) синтаксик анализ ясагыз, 2) аның схемасын сызыгыз һәм 3) төрен билгеләгез** / Сделайте 1) синтаксический разбор предложения, 2) укажите схему и 3) определите тип предложения (15 баллов. За каждое задание по 5 баллов).

*Бердән, атлар арыдылар, икенчедән, караңгы төште, өченчедән, яңгыр ява*. ( Ф.Х.)

Беренче җөмлә - беренчедән, атлар арыдылар. Ияс - атлар, хәбәре – арыдылар. Бердән – кереш сүз.

Икенче җөмлә - икенчедән, караңгы төште. Ияс – караңгы, хәбәре – төште. Икенчедән – кереш сүз.

Өченче җөмлә – өченчедән, яңгыр ява.  Иясе – яңгыр, хәбәре – ява. Өченчедән – кереш сүз.

Бу – күп тезмәле катлаулы кушма җөмлә. Хәбәрлекләр арасында бәйләүче чаралар – санау интонациясе.

[ ] = [ ] = [ ]

Һәр җөмлә кереш сүзләр белән катлауландырылган.  Һәр җөмлә - җыйнак, тулы, ике составлы, раслау җөмлә.

**V. Пунктуацион кагыйдәләргә мисаллар уйлап языгыз. /** Напишите примеры, соответствующие правилам  татарской пунктуации. (10 баллов, по 2 баллу за каждый правильный пример).

1) ***Ара, вакыт, күләм чикләрен белдерә торган исемнәр арасына сызык куела.***

*Казан – Мәскәү арасын 4 көн эчендә үттек.*

***2) Җөмлә ахырында килгән эндәш сүз алдыннан өтер куела.***

*Болай гына эш бармый шул, дустым.*

***3) Юнәлеш һәм чыгыш килешендәге сыйфат фигыль, исем фигыль белән белдерелгән сәбәп хәлләре ияртүче сүздән ераклашкан очракта аерымланалар һәм өтер белән  аерылалар.***

*Алсу, дәресләрен башкалардан алдан эшләп бетергәнгә, өйгә кайтырга рөхсәт сорады.*

*4)* ***Синтетик иярчен аергыч, тәмамлык җөмләләр баш җөмләдән өтер белән аерылмый***.

*Йомышлары бар укучылар укытучыны көтеп калдылар*.

***5) Җөмләнең иясе дә, хәбәре дә баш килештәге исем белән белдерелсә, ия белән хәбәр арасына сызык куела.***

*Сания – сыйныфта иң яхшы укучы.*

**VI. Хәзерге татар әдәби телендә теге яки бу эшнең, гамәлнең, процессның булу-булмау мөмкинлеге ничек белдерелә? Шул грамматик формалар турында языгыз. Мисаллар белән аңлатыгыз. /** Как передается модальное значение возможности процесса, действия в современном татарском литературном языке? Напишите об этом. Приведите примеры**.** (15 баллов. За описание и подтверждение примером каждой формы по 2 *балла; +3 балла за описание  модальности).*

*Җавап үрнәге:*

Татар телендә мөмкинлек модальлеге  эшнең булу – булмавы мөмкинлеген яки мөмкин түгеллеген аңлата. Ул түбәндәге грамматик формалар белән белдерелә ала.

*1)* –а/-ә кушымчалы хәл фигыль һәм ал ярдәмче фигыле белән. Мин дәрескә бара алам.  Мин олимпиадада  катнаша алмыйм.

*2)* –ырга/-ергә/-арга/-әргә инфинитив формасы һәм  мөмкин модаль сүзе.

Иртәгә дәрескә барырга мөмкин, ләкин  олимпиадага барырга мөмкин түгел.

Юклыкта: бармаска мөмкин.

*3)* –п кушымчалы хәл фигыль һәм бул ярдәмче фигыле ярдәмендә. Мәсәлән, Контроль эшне эшләп буламы?

*4)* –ырга/-ергә инфинитив формасы һәм бул ярдәмче фигыле ярдәмендә. Вакыт җитсә, укырга була.

*5)* –са шарт фигыль формасы һәм бул ярдәмче фигыле ярдәмендә. Бу форма күбрәк юклыкта кулланыла.

Хәзер кайгырмасагыз да була.

*6)* Тартым кушымчасы алган –у/-ү кушымчалы исем фигыль һәм бар, ихтимал, мөмкин модаль сүзләре ярдәмендә. Укытучының дәрестән иртәрәк чыгуы бар.

**VII. Түбәндәге фразеологизмнарның синонимнарын языгыз һәм мәгънәләрен аңлатыгыз. /** Напишите синонимы к фразеологизмам и объясните их значения. (10 баллов. Синоним и объяснение его значения оцениваются 2 *баллами*).

1) **Кара таңнан** – таң тишегеннән, караңгылы яктылыда һ.б. – бик иртә.
2) **Сөмсере коелу** – карага бату һ.б. – кәефсез булу
3) **Миннән киткәнче, иясенә җиткәнче** – эштер-өштер китерү, булса ярый, булмаса ярый - өстән-өстән генә эшләү, җиренә җиткермәү.
4) **Өстен чыгу** – алдан чыгу, өстенлек алу, узып чыгу – башкаларга караганда өстенлеге булу, яхшырак булу.
5) **Син дигәндә аяк идәндә** - баш өсте, син дигәндә себерке дә идәндә - кем өчендер барысын да эшләргә әзер булу.

**VIII. «Үз халкының тарихын белмичә яши торган адәм, нинди генә байлыкта һәм рәхәттә яшәсә дә, бу дөньяның матурлыгын тулысынча күрә алмас.» ( М.Максут) сүзләрен сез ничек аңлыйсыз? Шушы гыйбарәдә әйтелгән фикергә таянып, 80 сүздән артмаган инша языгыз. /**«Человек, незнающий историю своего народа, в каком бы богатстве и роскоши не жил, не сможет увидеть всю красоту этого мира» (Махмут Максут) Напишите, как вы понимаете данные слова автора? Опираясь на это выражение, напишите сочинение (не более 80 слов) (20 баллов).

| № | Сочинениене бәяләү критерийлары | Баллар |
|---|---|---|
| ***I*** | ***Иншаның эчтәлеге*** | |
| | Язманың эчтәлеге темага туры килә. Эчтәлеге тулысынча ачылган. Икедән артык дәлил бирелгән. | 4 |
| | Язманың эчтәлеге, нигездә, темага туры килә. Эчтәлеге ачылган. 1-2 гомуми дәлил бар. | 3 |

| | | |
|---|---|---|
| | Язманың эчтәлеген бирүдә җитди ялгышлар бар. 1 дәлил бар. | 2 |
| | Язманың эчтәлеге ачылмаган<br>**яки**<br>мисал буларак дәлил  язылмаган. | 0 |
| ***II*** | ***Иншаның тел ягы*** | |
| | **Язманың мәгънәви бөтенлеге, сөйләм бәйләнешлелеге, язу эзлеклелеге** | |
| | Эш мәгънәви бөтенлеге, сөйләм бәйләнешлелеге һәм язу эзлеклелеге белән характерлана:<br>– логик хаталар юк, язуда эзлеклелек бозылмаган;<br>– абзацларга бүленештә хаталар юк. | 2 |
| | Эш мәгънәви бөтенлеге, сөйләм бәйләнешлелеге һәм язу эзлеклелеге белән характерлана,<br>**ләкин**<br>1 логик хатасы бар,<br>**һәм/яки**<br>абзацларга бүленештә **1** урында хата бар. | 1 |
| | Язмада сөйләм үстерүгә омтылыш бар,<br>**ләкин**<br>логик хаталарның саны 1 дән артык,<br>**һәм/яки**<br>абзацларга бүленештә **2** урында хата бар. | 0 |
| | **Төгәллек һәм сөйләм матурлыгы** | |
| | Язмада фикер төгәл, төрле грамматик формалар кулланылган. | 2 |
| | Язмада фикер төгәл,<br>**Ләкин** бер генә төрле сөйләм калыпларыннан файдаланылган,<br>**яки**<br>язмада төрле грамматик формалар кулланылган,<br>**ләкин** фикер төгәллеге бозылган. | 1 |
| | Сүз байлыгыннан тиешенчә файдалана алмаган, бер үк төрле җөмлә калыпларын гына кулланган. | 0 |
| ***III*** | ***Грамоталылык*** | |
| | **Орфографик нормаларның үтәлеше** | |
| | Орфографик хаталары юк (яки тупас булмаган 1 хатасы бар). | 3 |
| | Хатасы 2 дән артык түгел. | 2 |
| | 3-4 хата җибәрелгән | 1 |
| | Хаталарының саны 4 тән артык | 0 |
| | **Пунктуацион нормаларның үтәлеше** | |
| | Пунктуацион хаталары юк (яки тупас булмаган 1 хатасы бар). | 3 |
| | 1-3 хатасы бар. | 2 |
| | 4-5 хатасы бар. | 1 |
| | Хаталарының саны 5 тән артык | 0 |
| | **Тел нормаларының үтәлеше** | |
| | Грамматик хаталары юк | 2 |
| | 1–2 хатасы бар | 1 |
| | Хаталарының саны 2 дән артык | 0 |
| | **Сөйләм нормаларының үтәлеше** | |
| | Сөйләмгә кагылышлы 1 генә хатасы бар | 2 |

| | | |
|---|---|---|
| | **2–3** хатасы бар | 1 |
| | Хаталарының саны **3** тән артык | 0 |
| | **Этикага кагылышлы нормаларның үтәлеше** | |
| | Этикага кагылышлы хаталары юк | 1 |
| | Хаталары бар (1 һәм 1дән күбрәк) | 0 |
| | **Язмада фактларны бирүдәге төгәллекнең үтәлеше** | |
| | Фактик хаталары юк. | 1 |
| | Фактик хаталары бар. | 0 |
| **Язма эш өчен максималь балл** | | **20** |